ПАЛАТА ИМУЩЕСТВЕННЫХ И ЗЕМЕЛЬНЫХ ОТНОШЕНИЙ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423190, с. Новошешминск, ул. Ленина, 37 «А»

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МИЛЕК ҺӘМ ҖИР МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ ПАЛАТАСЫ
423190, Яңа Чишмә авылы, Ленин урамы, 37 «А»

тел.факс.: (8-84348) 2-25-47, тел.факс: (8-84348) 2-27-67, Pizo.Nsm@tatar.ru

РАСПОРЯЖЕНИЕ | БОЕРЫК

2023 елның «24» апрель | № 227

Арендалана торган мөлкәтне милеккә сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендага ала торган күчемсез мөлкәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнец административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 29 декабрендәге 605-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы боера:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасыныц «Арендалана торган мөлкәтне милеккә сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендага ала торган күчемсез мөлкәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 10 февралендәге 71 номерлы карары белән расланган арендалана торган мөлкәтне милеккә сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары арендага ала торган күчемсез мөлкәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 2 бүлектәге 2.9.2 пунктының 2.9.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Күчемсез» сүзен «арендага бирелә торган» сүзенә алмаштырырга, «арендага бирелә торган» сүзен «мондый» сүзенә алмаштырырга, «күчемсез мөлкәт өчен һәм күчемле мөлкәт өчен кимендә өч ел» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге боерыкны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Милек һәм җир мөнәсәбәтләре
палатасы рәисе Н. В. Попкова